РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава Бетьковского сельского поселения
Рыбно-Слободского муниципального
района
индекс 422649 , с.Бетьки ,ул.Мира, дом 2
телефон

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке
авыл җирлеге башлыгы
индекс 422649, Бәтке авылы, Тынычлык ур.,
2 йорт
телефон

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, эл.адрес: Bet.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Бәтке ав. №2 3 ноябрь 2022 ел

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Яншык авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Бәтке авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Яншык авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2022 елның 18 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла дип билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Яншык авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

- торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );
- авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу );
- авыл җирлеге территориясен җәйге вакытта чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

5.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

6. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов